








# Мастер класс “Дәрестән тыш эшчәнлектә синквейн алымын куллану”

**Тел – белемнең ачкычы,**
**акылның баскычы.**

**Халык мәкале**

Мамадыш муниципаль районы
Катмыш урта гомуми белем
мәктәбенең башлангыч
сыйныфлар укытучысы Хузина
Илмира Ринат кызы

2017 ел

- 1.Тел
- 2.Мәңгелек ,үлмәс.
- 3.Дуслаштыра,берләштерә, кавыштыра.
- 4. И, туган тел, и матур тел!
- 5. Онытма!






# Нәрсә соң ул синквейн?

**Синквейн** - француз сүзе, «биш илһам», «биш уңыш» дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр. Билгеле план буенча языла, предметны (төшенчәне) ачыклый.



# Синквейн язу тәртибе

## Синквейн 5 юлдан тора


1 сүз

2 сүз

3 сүз

4 сүз

1 сүз





# Синквейн язу тәртибе



1 юл — **1 сүз**. Теманы ачыклаучы сүз, исем. (Кем? Нәрсә?)

2 юл — **2 сүз.** Теманы сурәтли торган 2 сыйфат (Нинди?)

3 юл — **3 сүз.** Темага хас булган 3 фигыль. (Нишли?)

4 юл — **4 сүз.** Темага карата үз мөнәсәбәтеңне белде-рүче фраза, җөмлә (афоризм, мәкаль, цитата)

5 юл — **1 сүз.** Темага карата 1 синоним сүз (нәтиҗә, ассоциация).



# Нәрсә турында синквейн язарга була?

- **Темасы төрле булырга мөмкин:**

❖ *табигать;*
❖ *әдәби герой, персонаж;*
❖ *әни, әти һәм башка гаилә әгъзалары;*
❖ *күңел халәте;*
❖ *дәрестә өйрәнгән тема;*
❖ *…*



# Укучылар



Көз

Сары, яңгырлы.

Коела, ява, салкыная.

Агачлардан алтын яфраклар коела.

Матурлык.

# Укучылар



Кыш


Салкын, карлы.

Туңдыра, шатландыра, бүләк итә.

Кыш бабай бүләкләр алып килә.


Яңа ел.

# Укучылар



**Авылым**
**Матур, чиста,**
**Үсә, яхшыра, яши.**
**Мин туган авылымны яратам**
**Ватан.**


# Укучылар иҗаты



Ризаетдин Фәхреттин
Белемле, күпкырлы
Укыткан, белгән, өйрәнгән
Мин Р.Фәхретдиннән үрнәк алам
Галим.

# Укучылар иҗаты

1. Чеби
2. Сары,йомшак.
3. Йөри,йөгерә,чүпли.
4. Мин аны кулыма алып сөям.
5. Нәни.









...И туган тел, и матур тел...
Татар теле



# Синквейнның нәтиҗәләлеге

- Тема буенча лексик материал үзләштерелә, сүзлек байлыгы арта;
- Эчтәлекне кыскача сөйләүгә әзерли;
- Тәнкыйди һәм креатив фикерләүне камил-ләштерә;
- Ассоциацияләр ярдәмендә алган белемнәр ныгытыла;
- Катлаулы информация гомумиләштерелә;
- Укучы үзен шагыйрь итеп хис итә;
- Бөтен укучы да яза ала.





# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

